| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Кудашевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Кодаш авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

10.03.2023 Кодаш авылы № 25-2

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, карар кабул итү тәртибе турында» 05.10.2020 елның 2-1 номерлы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актларны алдан юридик тикшерү һәм федераль законнарны мониторинглау, хокукый анализ, хокукый җайга салу юлларын мониторинглау нәтиҗәләре буенча Кодексның АИС системасы - Региональ законнар аналитигы ярдәмендә муниципаль норматив хокукый актка туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Җирле үзидарәнең сайланулы органы депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, карар кабул итү тәртибе турында»

05.10.2020 елның 2-1 номерлы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге советы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) 3 пунктның 2 абзацында, 4 пунктта, 5 пунктның 2 абзацында, 6 пунктның 1 абзацында, 7 пунктның 1,3 абзацында “Татарстан Республикасы Президенты” сүзләрен “Татарстан Республикасы башлыгы (Рәис)” сүзләре белән алыштырырга

2) 11 пунктның 1 абзацында “Татарстан Республикасы Президентына” дигән сүзләрне “Татарстан Республикасы Башлыгы (Рәис)” дигән сүзләр белән алыштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru , шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Кодаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмати стендта игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам

Совет Рәисе,

Авыл җирлеге башлыгы Ф.М.ШАКИРОВ